

Менә vзенен сихерле табигате белән алтын коз житте. Чынлап та алтын: жәй коне тосле 20-21 градус жылы (кичләре генә салкынча), агач яфраклары сихри тосләргә буяла, сукалаган иген кырлары гына кара тостә. Урманга килеп керv белән vзенен аерым кыелган яфраклар исе белән борын тишекләрен кытык-лый.

Гомбә жыю спорт кебек ул. Кvбебез тавышсыз ау белән шогыльләнә һәм шулай ике куяннын койрыгын беръюлы тота: ял да итә, кышка тәмле ашамлыклар да әзерли. Жиләге булсынмы, винеге булсынмы, гомбәсе... табигать кочагында чиксез рәхәт.

Козге агачлык һәм урман тирәләре янында машиналар туктаганын, кәр-жиннәрен тоткан кешеләр йоргәнен трассадан ук кvреп була. Һәрберсе чиксез шат. Татарстаннын халык шагыйре Равил Файзуллин белән Татарстан халык язучысы Гәрәй Рәхим дә гомбә жыярга яраталар икән. Табигать, дуслык, ижат – ботенесен тавышсыз ау сыйдыра.